Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2023 елның 14 августы №163

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында

Россия Федерациясенең 2004 елның 29 декабрендәге 190-ФЗ номерлы Шәһәр төзелеше кодексына, Россия Федерациясенең 2001 елның 25 октябрендәге 136-ФЗ номерлы Җир кодексына, Россия Федерациясенең 2006 елның 4 декабрендәге 200-ФЗ номерлы Урман кодексына, Россия Федерациясенең 2006 елның 3 июнендәге 74-ФЗ номерлы Су кодексына, Россия Федерациясенең 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ (14.07.2022 ред.) "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында", РФ Хөкүмәтенең 2006елның 9 июнендәге 363 номерлы Карары «Шәһәр төзелеше эшчәнлеген мәгълүмати тәэмин итү турында», «Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән,«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлеге " муниципаль берәмлегенең 2023 елның 3 мартындагы җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын тикшерү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар үткәрү нәтиҗәне исәпкә алып, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләрен расларга (https://fgistp.economy.gov.ru/).
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында дәүләт теркәвенә алганнан соң (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (kamskoye-ustye.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы Советының экология, аграр мәсьәләләр, табигый ресурслар һәм җирдән файдалану буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгы,
Кама Тамагы муниципаль районы Советы рәисе Н.А.Вазыйхов